ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 17 » 11 2023г. №1832/1

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан торакны - торак урыны, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урыны, күпфатирлы йортны - авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, торакны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында» 2021 елның 11 мартындагы 162 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, «Бинаны - торак бина, торак бинаны - яшәү өчен яраксыз һәм күп фатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану, бакча йортын – торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында Нигезләмәне раслау хакында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» Уставы нигезендә, норматив хокукый актны гамәлдәге Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2021 елның 162 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан торак урынны – торак, торакны - гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урыны, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатларында, бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче кушымтасын әлеге карарга кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

1.2. Карарның 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Ведомствоара комиссия составына шулай ук региональ торак күзәтчелеген (муниципаль торак контроле), санитар-эпидемиологик, экологик һәм башка куркынычсызлык, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәләрендә дәүләт контроле һәм күзәтчелеген үткәрүгә вәкаләтле органнар вәкилләре, алга таба - РФ Хөкүмәтенең 28.01.2006 ел, № 47 карарының 42 пунктында каралган Гадәттән тыш хәл зонасы чикләрендә урнашкан объектларның (торак урыннарның) җыелма исемлеге нигезендә биналарны тикшерү кирәк булганда, шулай ук билгеләнгән тәртиптә проект документациясенә һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза нәтиҗәләрен әзерләү хокукына аттестацияләнгән архитектура, шәһәр төзелеше һәм тиешле оешмаларның вәкилләре, экспертлар керә.»;

1.3. Карарның 2 нче кушымтасының 20 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Эш нәтиҗәләре буенча Ведомствоара комиссия биналарның һәм күпфатирлы йортларның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяләү турында түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- торак урынына куела торган таләпләргә һәм бинаның яшәү өчен яраклылыгына туры килүе турында;

- эксплуатацияләү барышында югалган торак урын характеристикаларын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары белән туры китерү максатында бинаны капиталь төзекләндерелергә, реконструкцияләнергә яисә яңадан планлаштырырга тиешле дип тану өчен (техник-икътисадый нигезләргә кирәк булганда) нигезләрне ачыклау турында;

- торакны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр ачыклау турында;

- торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану өчен нигезләр булмау турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм реконструкцияләнергә тиешле нигезләрне ачыклау турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм сүтелергә тиешле нигезләрне ачыклау турында;

- күпфатирлы йортны авария хәлендә дип тану һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле нигезләр булмау турында.».

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә урнашкан торакны - торак урыны, торакны - гражданнарның яшәве өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану өчен ведомствоара комиссия төзү турында» 2021 елның 11 мартындагы 162 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга .

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
вазифаларын башкаручы З.З. Гыйбадуллина

Якупов Р. М.
2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының

____________ 20___ ел № ___

карарына

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә торак бинаны – торак бина, торак бинаны гражданнар өчен яраклы (яраксыз) дип тану, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану максатында, бинаны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Самонина С. П. | Ведомствоара комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| Власова О.А. | Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары |
| Шакирова Э.А. | Ведомствоара комиссия секретаре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече |
| Ведомствоара комиссия әгъзалары: | |
| Долгих В.В. | Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында (Бөгелмә ТБ) кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте территориаль бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| Шаһиева З.М. | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе начальнигы урынбасары - Бөгелмә районара торак инспекциясе начальнигы (килешү буенча) |
| Лаптева С.В. | «Татарстан Республикасы техник инвентарьлаштыру бюросы» АҖ Әлмәт филиалының Ютазы бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Захаров А.Н. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура |

| | |
|---|---|
| | үсеше бүлеге начальнигы |
| Латыйпова Г.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы |
| Сәетгәрәева С.Р. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасары |
| Миңневәлиев Р.Н. | «Ютазагражданпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |